КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 1 апрель г.Казань № 242

Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим кертү турында

В связи с повышением уровня пожарной опасности в весенне-летний период, в соответствии со статьей 30 Федерального закона от 21 декабря 1994 года № 69-ФЗ «О пожарной безопасности» и статьей 25 Закона Республики Татарстан от 18 мая 1993 года № 1866-XII «О пожарной безопасности» Кабинет Министров Республики Татарстан ПОСТАНОВЛЯЕТ:

1. 2020 елның 10 апреленнән алып 17 маена кадәр Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим билгеләргә.

2. Янгынга каршы махсус режим үз көчендә булган чорда түбәндәгеләр тыела:

коры үлән һәм чүп яндыру;

урман янгыннары куркынычы янаган торак пунктлар, гражданнарның бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача коммерциячел булмаган берләшмәләре, урман кишәрлекләре белән чиктәш балалар сәламәтләндерү лагерьлары, икътисад объектлары, сәламәтләндерү оешмалары территорияләрендә, шулай ук урман паркы зоналарында, торфлы кишәрлекләрдә һәм урман массивлары белән чиктәш ачык территорияләрдә ачык утта (учаклар, мангаллар) ризык пешерү, 1 – 3 класстагы куркынычлы пиротехник эшләнмәләр куллану.

3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына:

ведомство буйсынуындагы объектларда территорияне коры үлән һәм чүптән чистарту буенча чаралар күрергә;

балансталы булган тышкы янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганакларының эшкә яраклылыгын тикшерергә;

махсус янгынга каршы режимның гамәлдә булу чорында янгын куркынычы тудыра торган эшләр үткәрүне чикләргә.

4. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына:

превентив янгын-профилактика чаралары комплексын планлаштырырга һәм үткәрергә;

массакүләм мәгълүмат чараларында торак пунктларда янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүнең проблемалы мәсьәләләрен яктыртырга, шулай ук янгын куркынычы чорында янгын куркынычсызлыгы чаралары турында халыкка мәгълүмат бирергә.

5. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенә:

урман янгыннары куркынычы янаган торак пунктларның паспортларын эшләүдә (актуальләштерүдә) җирле үзидарә органнарына консультация һәм методик ярдәм күрсәтергә;

торак пунктларны, икътисад объектларын табигый янгыннардан саклауны контрольгә алырга, шулай ук табигый янгын чыганакларын үз вакытында ачыклау һәм табылган көнне юкка чыгару буенча эш оештырырга;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Янгынга каршы режим турында» 2012 ел, 25 апрель, 390 нчы карары белән расланган Россия Федерациясендә янгынга каршы режим кагыйдәләре, шулай ук Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә һәм запастагы җирләрдә ачык ут куллану һәм учак ягу тәртибен раслау турында» 2016 ел, 26 гыйнвар, 26 нчы боерыгы таләпләрен исәпкә алып, коры үләнле үсемлекләрне ягу тәртибен аңлату буенча эшләр оештырырга һәм үткәрергә;

гражданнарның бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача коммерциячел булмаган берләшмәләре территорияләренең янгынга каршы торышына тикшерүләр үткәрергә;

космик мониторинг чаралары тарафыннан табылган янгыннар (термик нокталар) турындагы сигналларга вакытында җавап бирүне тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыкларына:

муниципаль берәмлектәге торак пунктларының янгыннан сакланышын ныгытуга юнәлдерелгән муниципаль хокукый актлар кабул итәргә;

һәр авыл җирлегендә патруль-контроль төркемнәре булдырырга һәм аларның эшен оештырырга, янгын куркынычы янаган чорга кадәр Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына тапшырырга тиешле төркемнәрнең эш графикларын эшләргә;

язгы-җәйге янгын куркынычы чорында халык арасында янгын куркынычсызлыгы чараларын агитацияләү һәм пропагандалау буенча эш үткәрергә, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары белән бу юнәлештә үзара хезмәттәшлек оештырырга;

янгын куркынычы сезоны башланганчы торак пунктларны һәм икътисад объектларын табигать янгыннарыннан саклау өчен минеральләштерелгән полосалар булдырырга, территорияләрне чүп-чардан һәм коры-сарыдан чистарту эшләрен тәгәлләргә;

гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссияләре утырышларында торак пунктларның янгын куркынычсызлыгы торышы турындагы мәсьәләләрне карап тикшерергә;

гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү территориаль подсистемасының муниципаль звенолары көчләре һәм чараларының табигый янгыннарны сүндерүгә әзерлеген тикшерүне үткәрергә;

урман янгыннары катлаулану чорына ихтыярый һәм муниципаль янгыннан саклау хезмәте әгъзаларының тәүлек буе кизү тору планнарын, шулай ук су сибү һәм янгын сүндерү өчен җайлаштырылган техниканы җәлеп итү планнарын төзергә;

табигый янгыннарга бәйле гадәттән тыш хәлләрне бетерү, торак пунктларны, икътисад һәм социаль инфраструктура объектларын урман янгыннарыннан саклау, шулай ук урман янгыннарын сүндерү өчен билгеләнгән көчләрне һәм чараларны муниципальара маневрлау буенча комплекслы өйрәнүләр үткәрергә;

табигый янгыннар барлыкка килгән очракта халыкка хәбәр итү һәм эвакуацияләү мәсьәләләрен эшләргә;

янгын куркынычы чорында кешеләрне вакытлыча урнаштыру пунктларының эшкә әзерлеген тикшерергә;

эвакуацияләнгән халыкның беренчел тормышын тәэмин итү планнарын эшләргә;

кешеләргә янгын турында хәбәр итү чараларының тотрыклы эшен тәэмин итәргә;

табигать янгыннары барлыкка килү куркынычы булганда һәм барлыкка килгәндә «Югары әзерлек» һәм (яки) «Гадәттән тыш хәл» эш режимнарын вакытында кертүне тәэмин итәргә;

Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, «Түбән Кама» милли паркы һәм Идел-Кама дәүләт табигый биосфера тыюлыгы җитәкчеләренә:

янгын куркынычы сезоны җиткәнгә кадәр махсус урман янгыннарын сүндерү техникасын һәм җиһазларын төзек хәлдә китерергә, аеруча саклаулы табигать территорияләре чикләрендә янгынга каршы профилактик чаралар комплексын вакытында үтәүне тәэмин итәргә;

торак пунктларның урман массивларына кушылу чикләре буйлап минеральләштерелгән полосаларны төзекләндерүдә республиканың җирле үзидарә органнарына ярдәм күрсәтергә;

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына янгынның һәр очрагы турында оператив мәгълүмат бирергә;

Горький тимер юлының Казан бүлегенә – «Россия тимер юллары» ААҖ филиалына янгын куркынычы чоры башланганга кадәр тимер юлларга бүлеп бирелгән полосаларда янгынга каршы профилактик чаралар комплексын вакытында үтәүне тәэмин итәргә, шулай ук тимер юлларга бүлеп бирелгән полосаларында янгын чыгу очраклары турында оператив мәгълүматны Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына тапшырырга.

6. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына:

муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары белән берлектә урман янгыннарын кисәтүгә һәм алар белән көрәшкә йөз тоткан оештыру-техник чаралар үткәрүне тәэмин итәргә;

урман массивларында һәм алар янында урнашкан табигый һәм ясалма сулыклардан янгынга каршы техника белән су алу өчен мәйданнарны уңайландыруны дәвам итәргә;

урман янгыннарының башлангычында аларны үз вакытында табып алу, туктату һәм бетерүгә юнәлгән оператив чаралар күрүне тәэмин итәргә;

урман янгыннарын сүндерү өчен янгынга каршы техниканы, транспорт чараларын, шулай ук урман янгыннарын сүндерү планы нигезендә коммерциячел һәм коммерциячел булмаган оешмалар хезмәткәрләрен һәм гражданнарны җәлеп итәргә;

республиканың җирле үзидарә органнарына торак пунктлары урман массивларына тоташкан урыннарда чик буенча минераллаштырылган полосаларны урнаштыруда булышлык күрсәтергә;

янгын куркынычы сезоны башланганчы:

үз ведомствосындагы урман фондында эшләр башкаручы учреждениеләр һәм оешмаларның көчләрен һәм чараларын урман янгыннарын сүндерүгә әзер булуын тикшерүләр үткәрергә;

гамәлдәге нормалар нигезендә янгын-химия станцияләрен шәхси состав белән тулыландырып бетерергә, шәхси составны өйрәтүләр оештырырга;

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы ведомствосындагы «Урман хуҗалыгы» учреждениеләренеке булган махсус урман янгынын сүндерү техникасын һәм җиһазларны кышкы саклаудан соң техник төзек хәлгә китерергә;

урманнарны авиа күзәтеп йөрү чараларын гамәлгә ашырырга контракт төзергә.

7. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына, торак пунктларда һәм урман массивларында янгыннар чыгуны кисәтү максаты белән:

ведомство буйсынуындагы учреждениеләр җитәкчеләренә Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә һәм запастагы җирләрдә ачык ут куллану һәм учак ягу тәртибен раслау турында» 2016 ел, 26 гыйнвар, 26 нчы боерыгы таләпләрен җиткерергә;

авыл хуҗалыгы оешмалары һәм фермер хуҗалыклары тарафыннан авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә һәм алар янәшәсендәге урман массивларында язгы кыр һәм урып-җыю эшләрен уздырганда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәүгә юнәлдерелгән чаралар комплексын гамәлгә ашырырга;

авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә рөхсәт ителмәгән урылган кыр, коры үлән һәм чүп ягуны булдырмау һәм ачыклау эшләрен оештырырга;

урман һәм торф массивларына, дала полосасына, автомобиль һәм тимер юлларга якын торган урыннарны сукалау;

авыл хуҗалыгы предприятиеләре территорияләрен чүп-чардан һәм коры-сарыдан чистарту, авыл хуҗалыгы формированиеләре балансында булган янгын сүндерү һәм янгын сүндерү максатлары өчен җайлаштырылган техниканы тәүлек буе кизү торуын оештыру (кирәк булганда), шулай ук төзек булмаган янгын

техникасын ремонтлау.

8. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына, Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына, шулай ук Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә:

2019 елның 30 апреленнән алып 10 маена кадәр янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәү өлешендә урман-парк зоналарында һәм гражданнар күпләп ял иткән урыннарда патрульләр оештырырга һәм үткәрергә;

халык арасында, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары аша, язгы-җәйге чорда торак пунктларда һәм урманнарда янгыннарны профилактикалау мәсьәләләре буенча максатчан эш оештырырга;

гражданнар белән җыеннарда янгыннарны сүндерү һәм гадәттән тыш хәл зонасыннан эвакуацияләү буенча хәрәкәтләргә өйрәтү буенча дәресләр үткәрергә;

табигый янгыннарның торак пунктларга һәм икътисад объектларына күчүе куркынычы булганда практик гамәлләр эшләү белән муниципаль, ведомство, шәхси һәм ихтыярый янгын сүндерү формированиеләренең, янгын-химия станцияләренең һәм урман хуҗалыкларының әзерлеген тикшерүне оештырырга.

9. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына урман-парк зоналарында һәм гражданнар күпләп ял иткән урыннарда патрульләр үткәрү чорында Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына, Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына һәм Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә законнарда каралган тәртиптә булышлык күрсәтергә тәкъдим итәргә.

10. Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына:

янгын куркынычы сезоны башланганчы төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлларына бүлеп бирелгән полосаларны һәм уңайлаштыру элементларын янгыннан саклауның кирәкле чараларын күрергә;

төбәк әһәмиятендәге автомобиль юллары кырыйларын, сөзәк җирләрне һәм бүлеп бирелгән полосаларны системалы рәвештә чүптән, кирәксез үләннән һәм агач-куактан чистартуны тәэмин итәргә.

11. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына:

язгы-җәйге чорда торак пунктларда һәм урманнарда янгын куркынычсызлыгын саклауны пропагандалый торган видео- һәм аудиороликлар эшләргә һәм аларны республика, шәһәр һәм җирле теле- һәм радиоканалларда («Татмедиа» ААҖ филиалларында) тапшыруны тәэмин итәргә;

басма массакүләм мәгълүмат чараларында халык өчен куркынычсыз тәртип кагыйдәләрен бастыру өчен «ГТХМ кисәтә» профилактик рубрикасын оештырырга.

12. Балансларында урман янгыннары куркынычы янаган балалар сәламәтләндерү лагерьлары булган министрлыклар, ведомстволар, предприятие һәм оешмалар җитәкчеләренә:

лагерьның вазыйфаи затлары арасыннан янгынны үз вакытында ачыклау өчен патруль төркемнәре төзергә;

җирле үзидарә, Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм

гадәттән тыш хәлләр министрлыгы органнарына янгын чыгу турында хәбәр итү тәртибен эшләргә;

табигый (урман) янгын чыккан очракта хәбәр итү һәм лагерь территориясеннән балаларны эвакуацияләү тәртибен эшләргә.

13. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин